| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ КЕРЛИГАЧСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «КИРЛЕГӘЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 19 сентябре** **№ 10**

«Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 13 ноябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, "Кирлегәч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар турында кодексының 2.2, 2.6, 2.7, 3.2, 3.4, 3.6, 3.6, 3.6, 3.7, 4.4 статьяларында (җирлекләр милкендәге торак булмаган фонд объектларына карата) каралган «Кирлегәч авыл җирлеге»муниципаль берәмлегендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле затларның вазыйфаи инструкцияләренә кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

3. «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2014 елның 5 ноябрендәге «Кирлегәч авыл җирлеге «муниципаль берәмлегендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында» 14 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы Кирлегәч авылы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

(http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы С.Р.Сәлахова